КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 октябрь г.Казань № 1295

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләр башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2013 ел, 23 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләр башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләр башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2013 ел, 23 апрель, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 июль, 461 нче; 2018 ел, 10 гыйнвар, 1 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләр башкаруның административ

регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның өченче абзацында «, учреждениеләр һәм оешмалар» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин